**Яр Чаллы шәһәре Хакиме**
**карары**

**№М 108**
**25.03.2020**

Шәһәр өмәсе
үткәрү турында

Яр Чаллы шәһәре территориясен төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар чистартуны оештыру максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 бүлегенең 25 пункты, 17 статьясындагы 2 бүлеге, шәһәр Уставының 24 статьясындагы 3 бүлеге, 35 статьясындагы 1 бүлегенең 16 пункты, Шәһәр Советының 2006 елның 23 ноябрендәге 16/11 номерлы карары белән расланган Гражданнарны шәһәр өчен социаль әһәмияткә ия эшләрне ирекле нигездә башкаруга җәлеп итү тәртибе турындагы нигезнамә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2020 елның 18 апрелендә 08.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр Яр Чаллы шәһәре территориясен төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар чистарту буенча шәһәр өмәсе (алга таба – өмә) үткәрергә.

2. Гражданнарны шәһәр өчен түбәндәге социаль әһәмияткә ия эшләрне башкаруга җәлеп итәргә: яфракларны җыю, чүпләрне җыю, агачлар һәм куаклар утырту, агачларны һәм куакларны санитар кисү.

3. Эшләрне үткәрү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә: парклар, скверлар, яр буйлары һәм бульварлар, шәһәр магистральләре буйлап яшел зоналар, күпфатирлы йортлар янәшәсендәге территорияләр, Кама, Мәләкәс, Шилнә, Челна елгаларының яр буе зоналары.

4. Башкарма комитетка тәэмин итәргә:

1) шәһәр өмәсен оештыру һәм үткәрү буенча чаралар планын раслауны;

2) өмә оештыруны һәм үткәрүне;

3) әлеге карарны «Челнинские известия» һәм «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев